...ВОЛГОГРАДСКАЯ ОБЛ...

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

Ленин — Сталин эше өчен көрәшкә хәзер бул!

Будь готов!

Яш Ленинче

Орган Татобкома ВЛКСМ и Наркомпроса ТАССР

21 ИЮНЬ, 1940 ЕЛ
№ 46 (968)

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Мәгариф Халык Комиссариаты органы



4 нче ясалма каучук заводының эшчеләр шәһәрчеге.
И. Галиев фотосы.

Татарстанның XX еллыгына хәзерлек

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ЭЗЕ БУЕНЧА МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНЫҢ ПОХОДЛАРЫ

1918 нче елда эчке контрреволюцион партияләр белән берләшкән хәлдә чит ил интервентлары яш советлар республикасын җимерү өчен көчле сугыш башладылар. Большевиклар партиясе һәм аның юлбашчылары Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә миллионнарча пролетариат Советлар Россиясен саклау өчен көрәшкә кузгалды.

1918 нче елның икенче яртысында Татарстанның күп кенә өлешләре гражданнар сугышы уты эчендә калды. Чех-словаклар һәм ак гвардеецлар тарафыннан башланган мятеж урта Волганы, Каманың урта һәм түбәнге агымнарын чорнап алды. Ак гвардеецлар авыллардагы советларны туздырып, анда полиция властьлары урнаштырдылар. Партия һәм совет работникларын аттылар, җирләрне алпавытларга кире кайтарып бирделәр. Алар Казанны сугышып алып Москвага таба юнәлмәкче булдылар.

Үзәктәге коммунистлар һәм эшчеләр отрядлары Казанны саклап калу өчен ярдәмгә килделәр. Казан шәһәре янында 5 нче Кызыл Армия отряды оештырыла. Бу отряд чех-словакларга һәм ак гвардеецларга бик нык удар биреп, аларны Татарстан республикасы территориясеннән куып чыгара.

Гражданнар сугышы чорында большевиклар партиясе бик яхшы полководецларны, лигендар геройларны югалтты. Бу полководецларның героик эшләре безнең совет яшьләре өчен үрнәк булып тора. Татарстан территориясендәге гражданнар сугышы геройларының (Ян Юдин, Маркин, Олькеницкий) сугышчан тормыш юллары белән танышу—Татарстан яшьләренең бурычы.

1940 нчы елның җәйге каникул вактында Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты карамагындагы балаларның туристик-экскурсия станциясе гражданнар сугышы эзе буенча мәктәп балаларының походларын оештыра.

Походлар вактында мәктәп балалары безнең гүзәл өлкәбезнең тарихы белән танышалар. Гражданнар сугышы булган урыннарны карыйлар, сугышка катнашучылар белән беседалар уздыралар.

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты карары буенча районнарда оештырыла торган походлар белән ВЛКСМ ның район Комитеты, район мәгариф бүлеге һәм район Хәрби Комиссариат работниклары катнашы белән төзелгән штаб җитәкчелек итә.

Елизарова.
Балаларның өлкә туристик-экскурсия станциясе директоры.

ВЛКСМ ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ XI НЧЕ ПЛЕНУМЫ ТУРЫНДА

Шушы көннәрдә генә ВЛКСМ Үзәк Комитетының XI нче пленумы үзенең эшен тәмамлады. Пленум түбәндәге мәсьәләләрне карады:

1. Комсомол активы белән эшне яхшырту һәм шуңа карата комсомол аппаратының эшен үзгәртеп кору турында.
2. Комсомол оешмаларында членлык взносларын түләүнең торышы турында.
3. Колхозларда су җыю урыннары төзү буенча колхоз комсомол оешмаларының эше турында.

Беренче мәсьәлә буенча ВЛКСМ Үзек Комитетының секретаре иптәш Н. А. Михайлов доклад ясады.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тормышка үткәрүдә комсомол, большевиклар партиясенең данлы җитәкчелеге астында, бик зур эшләр башкарды. Ленин—Сталин комсомолы—яшьләрнең массовый оешмасы. Аның сафлары көннән-көн үсә. Бары тик соңгы ике ел эчендә генә дә комсомол ике тапкырдан артыгракка үсте. Хәзер аның сафларында 10 миллионнан артык яшьләр һәм яшь кызлар санала. Комсомол—алдынгы совет яшьләренең үзешчән оешмасы.

Иптәш Михайлов үзенең докладында комсомолның яшьләргә йогынты ясавы турында, большевиклар партиясенең сугышчан ярдәмчесе булу йөзеннән комсомолның роле турында бик ачык мисальләр китерде. Мөһим политик кампанияләрдә меңнәрчә комсомол активлары кайнар рәвештә катнаштылар.

Иптәш Михайлов үзенең докладында комсомол оешмаларының җитәкчеләре—ВЛКСМ ның район, шәһәр һәм өлкә комитетларының түләүле работниклары булуын, ә активның җитәкчелек эшкә аз тартылуын күрсәтте. Һәм бу, билгеле, дөрес түгел. Менә шуның өчен дә безне партия, иптәш Сталин комсомолның иҗад эшенә, эчтәлекле эшенә миллионнарча комсомолецларны һәм комсомолкаларны тартырга өйрәтә.

Хәзер җитәкче эшләргә үзешчән активның киң катлавын тартырга кирәк. Барлык комсомолецларның да яшьләр союзында актив рәвештә эшләве кирәк. Һәркем үзенең оешмасыннан бирелгән порученинене төгәл итеп, срогында үтәргә тиеш. Шәһәр комитетларында һәм район комитетларында комсомолның бөтен эшен алып баручы зур актив булдырылырга тиеш. Комсомолның актив эшенә оешманың барлык членнарын кыю рәвештә тарту белән без комсомолның эшкә сәләтле булуын гына көчәйтербез.

Аннан соң иптәш Михайлов яшьләр арасында хәрби-физкультура эшенең җитешсез якларын күрсәтте. Бик еш кына болай була. Комсомолецлар хәрби поход оештырырга уйлыйлар. Походка катнашучыларны нәрсәгә булса да өйрәтү, нинди дә булса хәрби күнегү үткәрүдә ярдәм итү урнына хәсрәт оештыручылар походны күңел ачу прогулкасына әверелдерәләр. Билгеле, болай эшләргә ярамый. Комсомолецларны һәм комсомолкаларны сугышчан тормышка чыдамлы һәм нык итеп тәрбияләргә кирәк.

Икенче мәсьәлә буенча—„Комсомол оешмаларында членлык взносларын түләүнең торышы турында“—ВЛКСМ Үзәк Комитетының секретаре иптәш Н. Н. Романов доклад ясады.

ВЛКСМ Уставында, членлык взносы түләү—комсомолда торуның иң төп шартларының берсе,—диелгән. Устав һәрбер комсомолецның вактында взнос түләвен таләп итә. Членлык взнослары түләү—ул яшьләр союзына материаль ярдәм итү генә түгел, ә һәрбер комсомолецның мөһим бурычы да. Төгәл итеп һәм срогында взносларын түләүче, оешманың дисциплиналы члены булуын күрсәтә.

Иптәш Романов үзенең докладында, ВЛКСМ Уставының членлык взносларын вактында түләргә таләп итүенә дә карамастан, аны бозу фактлары булуын да күрсәтте. Ни өчен соң алай булган? Чөнки взносларны вактында түләүнең политик әһәмиятен комсомолецларга аңлатмаганнар. Соңгы вакытларда комсомол сафларына бик күп яшьләр керделәр, ә яңа керүчеләргә, членлык взносларын вактында түләү—ВЛКСМ Уставының иң төп таләпләренең берсе икәнлеген өзлексез рәвештә аңлатырга кирәк.

Комсомол уставын тулысынча үтәү, членлык взносларын вактында түләү, һәр вакытта да һәм һәр җирдә дә дисциплиналылыкның, намуслылыкның үрнәге булу — һәрбер комсомолецтан да сорала торган нәрсә менә шул. Бу яшьләр оешмасын ныгыта, аның оешканлыгын һәм сугышчан сәләтлелеген күтәрә.

„Колхозларда су җыю урыннары төзү буенча колхоз комсомол оешмаларының эше турында“ гы доклад белән ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре иптәш Ф. И. Наседкин чыгыш ясады.

Моннан ике атна элек газеталарда Талов колхозчыларының су җыю урыннары төзү турындагы мөраҗәгатләре чыккан иде. Ә хәзер бу эшкә Советлар Союзының төрле өлкәләрендәге йөзләрчә һәм меңнәрчә колхозлар керештеләр.

Халыкның бу яңа хәрәкәтендә комсомолның роле гаять зур. „Һәрбер колхозга—үзенең су җыю урны“—комсомолның үз алдына куйган бурычы менә шул. Бу турыда иптәш Наседкин үзенең докладында сөйләде.

Күп кенә комсомол оешмалары бу эшкә чын-чынлап керештеләр дә инде.

Мәсәлән, Тамбов өлкәсенең Жердовский районы, „Путь Ленина“ һәм „Красное знамя“ артельләренең комсомолецлары бергәләшеп ике ташландык буаны һәм ташландык ясалма күлне элекке хәленә кайтардылар.

Чкалов өлкәсе, Краснохолмский районының „Путь Сталина“ артеле, Буденный исемендәге артеле комсомолецлары һәм колхозчылары яңа буалар төзиләр.

Һәм, билгеле, комсомол тарафыннан алып барыла торган бу зур эштә пионерлар да катнашырга тиешләр.

Балалар, укытучылар белән, агрономнар белән киңәшегез, буа тирәсенә нинди агачлар утырту яхшырак булуын, буада нинди кошлар һәм балыклар үрчетү файдалырак булуын белегез һәм эшкә керешегез!

Олырак балалар буалар төзүдә һәм су җыю урыннарын чистартуда комсомолецларга ярдәм итә алалар.

***

ВЛКСМ Үзәк Комитетының XI нче пленумы барлык өч мәсьәлә буенча да карарлар кабул итте. Хәзер XI нче пленум карарлары нигезендә комсомол оешмалары, җиң сызганып, яңа көч белән үзләренең көндәлек эшләренә керешерләр.

Ленин—Сталин партиясе җитәкчелеге астында булган, бөтен совет яшьләре белән нык бәйләнештә булган комсомол ватаныбызны яңа гүзәл эшләр белән шатландырыр.

ЛИТВА ТӨРМӘСЕННӘН ПОЛИТИК ТОТКЫННАРНЫ АЗАТ ИТҮ

КАУНАС, 18 июнь. Бүген 18 сәгаттә Каунастагы каторга төрмәсеннән 104 политик тоткын азат ителде. Аларның күбесе төрмәдә 8әр—14 әр ел утырганнар.

Төрмә бинасы янында политик тоткыннарны меңнәрчә хезмәт ияләре каршы алдылар. Каршы алучыларның күбесе елый. Азатлык өчен көрәшүчеләрне халык шатлыклы „Вале!“ („Ура!“) тавышлары белән каршы ала.

Элекке политик тоткын Снешкус ТАСС хәбәрчесенә болай дип белдерде: „Мине өч тапкыр кулга алдылар. Мин төрле төрмәләрдә утырдым. Бу төрмәгә мин үзара ярдәмләшү турында Совет—Литва договорына кул куелганнан соң эләктем. Мин—Советлар Союзы турында чын сөйләвем өчен утыртылдым. Төрмәдә безгә бер нинди әдәбият та, хәтта сүзлекләр дә укырга рөхсәт итмәделәр. Безне ерткычларча кыйнадылар, карцерларга утырттылар, ашатмыйча калдырдылар, туганнарыбыз белән күрешү хокукыннан мәхрум иттеләр. Моннан өч көн элек, төрмәдә утырган вакытта, мин һәм минем иптәшләрем Совет танкларының һәм самолетларының тавышын ишеттек. Безнең бу вакыттагы шатлыгыбызны әйтеп бетерү кыен. Без Сметонаның канлы төрмә режимына чик куелганлыкны аңладык.

Хәзер мин иректә. Мин үземнең халкым өчен, аның язмышы өчен һәм аның Советлар Союзы тәэмин итә торган киләчәге өчен шатмын“.

Литваның башка төрмәләрендә политик тоткыннарны азат итү иртәгә көтелә.

СТАДИОНДА

Көн матур булмаса да Казанның спорт сөючеләре „Динамо“ стадионына агыла башладылар.

Сәгат 6. Судья Власов кулына туп тотып уен кырының уртасына чыкты да һәр ике команданы чакырып свисток кычкыртты. Кызыл майкалы свердловчылар судья янына барып тезелделәр. Алар артыннан казанлылар чыкты.

Уен башланды. Кем җиңәр? Әле бу берәүгә дә билгеле түгел. Кайберәүләр:

— Казанлылар җиңәр,— дисәләр дә, караучыларның күбесе:

— Кара, кунаклар ничек яхшы уйныйлар,—дип свердловчыларның җиңүенә ышандырырга телиләр.

Уенның беренче бүлеге 0:0 исәбе белән бетте. Болай булгач, икенче бүлектә уен тагын да кызу булачак. Чыннан да, икенче бүлек башланып күп тә үтмәде, Казан вратаре Коляпин сеткадан беренче тупны алып бирде һәм уен бетәргә бер минут калгач свердловчылар икенче тупларын керттеләр.

Бу ярыш 2:0 исәбе белән кунаклар файдасына тәмамланды. *Х. Р.*

18 нче июнь.

Казанның М. Горький исемендәге Культура һәм Ял Паркында.
И. Галиев фотосы.

КАРЕЛ-ФИН СОВЕТ РЕСПУБЛИКАСЫНДА БӨТЕН ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

Моннан өч айлар элек союз республикаларының туганнар семьясенә уникенче союз республикасы—Карел-Фин Союз республикасы керде.

Хәзер карел-фин халыклары СССР һәм республиканың Верховный советларына үзләренең депутатларын сайладылар.

Сокланырлык итеп җыештырылган сайлау участкаларының ишекләре сайлаучылар өчен кунакчыл рәвештә ачылдылар.

Ун меңнәрчә сайлаучылар үзләренең тавышларын карел-фин халкының иң яхшы вәкилләренә, коммунистларның һәм партиясезләрнең җимерелмәслек блогы кандидатларына бирәләр.

Карел-фин халкы республиканың Верховный советына үзенең беренче кандидаты итеп, бәхетле тормыш китерүче кешене—хезмәт ияләренең юлбашчысы бөек Сталинны күрсәтте.

Республиканың хезмәт ияләре Карел-Фин ССР Верховный советына кандидат итеп бөек Сталинның сугышчан көрәштәшләрен зур күтәренкелек белән күрсәттеләр,

СССР һәм Карел-Фин республикасының Верховный Советына күрсәтелгән кандидатлар арасында без милли геройларның, Тойво Антикайненның, орденлы Илмар Текурның, Советлар Союзы Герое И. Д. Папанинның, урман кисүче—күренекле стахановчы Евдокия Непинаның, комсомолка Зоя Тяпкинаның һәм башкаларның исемнәрен очратабыз.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Германия командованиесе сводкасы

БЕРЛИН, 19 июнь. Германия информация бюросы Германиянең кораллы көчләренең верховный баш командующие ставкасының түбәндәге сводкасын тапшыра:

„Франция армиясенең тагын да таркалуы дәвам итә. Германиянең моторлаштырылган частьләре Нормандиядә Шербургны алдылар. Ренн якынында алар Бретаньга барып җиттеләр, көньяк юнәлештә Ле-Манны үттеләр. Луара елгасы берничә урыннан кичелде. Бургундиядә Германиянең моторлаштырылган частьләре Лионга таба баралар. Мюльгаузеннан көнбатышта Германиянең Бельфордан һөҗүм итеп килүче танк һәм моторлаштырылган дивизияләре Рейннең югаргы агымы районында хәрәкәт итүче һәм Монсгер якынында Вогезыга таба үткән частьләр белән кушылырга омтылалар. Нанси шәһәре алынды һәм Рейн-Марна каналы киң фронт булып үтелде. Мажино линиясендә Диденгофенның ике ягында да дошман әле каршылык күрсәтә. Пикировать итүче бомбардировщиклар һәм истребительләр берләшмәләре дошманның Лотарингиядә чолгап алынган гаскәрләренең каршылыгын бастырырга омтылып, ныгытмаларга, позицияләргә, тимер юлларга, җыелып тора торган гаскәрләргә һәм походтагы колонналарга һөҗүм иттеләр. Шербург янында бомбалар төшү нәтиҗәсендә 10 мең тонна авырлыктагы сәүдә пароходы батырылды.

Германия авиациясе Англиядәге күп аэродромнарны бомбага тотты. Темза тамагында нефть саклый торган урыннар бомбага тотылдылар һәм аларга ут капты. 19 нчы июньгә каршы төндә Англия самолетлары Германиянең төньягына һәм көнбатышына һөҗүм итеп, хәрби булмаган объектларга яңадан бомбалар ташладылар. Гражданнар арасыннан 18 кеше үтерелде.

Кичә дошман һавада 6 самолетын югалтты. Германиянең 5 самолеты үз базаларына кайтмады“.

Казанда уздырылган хатын-кызлар кроссында беренчелекне алучы Екатерина Морозова.
И. Галиев фотосы.

ЛЕНИНГРАДТА БАЛАЛАРНЫҢ ДИҢГЕЗ ПОРТЫ

Петровск портында, Нева елгасының Балтыйк диңгезенә коя торган урнында, тиздән балаларның диңгез һәм елга порты төзү эше башлана. Бирeдә пароходлар туктау урны янындагы бухтада, чын сугыш караблары, канонер көймәләре, катерлар, мониторлар торырлар. Яш моряклар карамагында тагын яхталар, шлюпкалар, байдаркалар, моторлы көймәләр, пар белән йөри торган буксирлар, елга газоходлары булачак.

Портта караб ясау һәм аны суга төшерү корылмасы булачак. Шунда ук балалар чертежлар буенча яхталар, көймәләр, карабларның модельләрен төзә алырлар. Балалар порты территориясендә диңгез вокзалы, яхта-клуб, порт зданиеләре төзеләчәк.

Порт Кечкенә Балтыйк дип аталачак. Ленинградның яш моряклары кызыл байраклы Балтыйк флотының командирлары һәм кызыл флотчылары, су транспортының тәҗрибәле җитәкчеләре ярдәмендә хәрби-диңгез эшләрен үзләштерәчәкләр.

КҮПМЕ КАРАБЛАР БАТЫРЫЛДЫ

Германиянең кораллы көчләренең Верховный командованиесе хәбәр итүенә караганда, Норвегиядәге сугышлар чорында Германиянең хәрби-диңгез флоты һәм авиациясе тарафыннан союзникларның 1 авианосецы, 1 крейсеры 10 миноносецы, 1 су асты көймәсе истребителе, 19 су асты көймәсе батырылган. Норвегиянең 11 сугыш карабы юкка чыгарылган.

Бу сугышларда Германия 3 крейсер, 10 эсминец, 1 миноносец, 6 су асты көймәсе һәм 15 кә якын кечкенә сугыш һәм ярдәмчел караблар югалткан.

Безнең павильон

БӨТЕНСОЮЗ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

А. АЛИШ.

III. ТЕХНИКА ЗАЛЫ

Бөек юлбашчыбызның тормыш иптәше, халык мәгарифына күп хезмәт куючы Надежда Константиновна:

„Техника безнең көн-күрешебезгә һаман тирәнрәк керә бара, безнең балаларыбызны кече яштән үк чолгап ала, аларда кызыксыну тудыра, аларның уйларын алга этә“,—дигән иде.

Техника залы бу сүзләрне тулысы белән раслый. Яш конструкторлар авыл хуҗалыгы машиналарын тагын да яхшырта төшү, яңа төр машиналар уйлап чыгару өстендә эшлиләр. Менә алар техника батырлары!

Төркмәнстандагы тулы булмаган урта мәктәпнең 7 нче классында укучы Бәйрәм Али тырма моделе ясый. Аның моделе „зиг-заг“ тырмасына бик охшый, ләкин Бәйрәм Али тырмасындагы тешләрен авышлыгын кирәк вакытта теләгәнчә үзгәртеп була.

Мар—Посадский (Чуваш республикасы) балалар техник станциясендәге яш техниклар түгәрәге утильсырьедан трактор җыный. Түгәрәк 30 лап укучыны трактор йөртергә өйрәтә.

Бер көнне Гриша үз колхозлары кырында комбайн күрә. Бу зур машинаның механизмнарының сәгат кебек төгәл хәрәкәт итүләре аны бик нык кызыксындыра. „Әгәр дә кleverны дә шулай урып җыештырсаң, клевер комбайны ясасаң“,—дигән уй аның башына килә. Шул вакыттан бирле клевер комбайны эшләү аның һич уеннан чыкмый. Ул техник станциягә бик еш йөри башлый, чертежлар сыза, төрле расчетлар ясый.

Ике ел буе ул үзенең иптәше белән тырышып эшли. Нәтиҗәдә кечкенә электр мотор ярдәмендә хәрәкәт итә торган комбайн моделен эшли. Модельнең 300 дән артык детале бар.

Одессадагы урта мәктәпнең 8 нче классында укучы Вася Морозов чөгендер җыю комбайны төзи. Бу модельнең оригиналы 1939 нчы елда Нью-Йорктагы бөтен дөнья күргәзмәсенә дә куелды.

Ленинград укучысы Саша Осиповның автоматик санагычы бик кызыклы гына. Модельдә дуңгыз абзарына тар гына юл бара. Фанердан кисеп эшләнгән дуңгыз фигуралары тасмага беркетелгәннәр. Бу тасма электромотор ярдәмендә хәрәкәткә китерелә, дуңгыз фигуралары йөгерә башлый. Йөгерү юлларында алар фотоэлементтан төшә торган яктылыкны бик азга гына булса да томалыйлар, счетчик эшли башлый һәм аның тәрәзәсендә яңа цифр килеп чыга.

Тбилиси шәһәрендәге урта мәктәпнең 7 нче класс укучысы Мосесов Ким 32 миллиграмм авырлыгындагы электромотор ясый. Ул үзенең электромоторын „Лилипут“ дип атый.

Механизация залында болардан башка модельләр дә бик күп. Шул нәни машиналар совет балаларының техниканы үзләштерүгә ашкынып торуларын, зурлар белән бер сафта көрәшеп, аны алга илтергә, кешелек дөньясына ныклы хезмәт күрсәтергә теләүләрен бик ачык күрсәтәләр.

ТАБЫШ

15 яшьлек Сережа Бабушкин үзенең иптәшләре—Женя Балакиров һәм Геня Тахамов белән үзләренең йортлары янындагы бакчада (6 нчы Август урамы, 5 нче йорт), уйнаганда пияла савыт тапканнар. Аның эчендә унар сумлык 6 алтын акча яшерелгән булган.

Дуслар үзләренең табышларын милиция идарәсенә илтеп тапшырдылар.

Казан.

Өлкән иптәш

КАЗАНДАГЫ 13 НЧЕ НОМЕРЛЫ УРТА МӘКТӘПНЕҢ РУС ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫ СЕМЕН ИОНИННЫҢ УКЫТУЧЫЛЫК ХЕЗМӘТЕНӘ БЫЕЛ 35 ЕЛ ТУЛДЫ.

Дәрескә керергә звонок булды. Зал бушап калды. Класска уртача буйлы, кара чәчле (бу чәчләргә күптән инде чал төшкән) каралҗым йөзле, күзлек кигән кеше керде. Барсы да урыннарыннан тордылар. Укытучы елмайды, ул ниндидер шаян сүз әйтте. Аның бу сүзеннән барсы да күтәрелеп көлделәр.

Класста бары аның гына, чәченә чал төшкән карт укытучының гына, балаларны яратучы, алардан үзен яраттыра алучы, сөйли торган материалын яхшы белүче, үзенең акыллы һәм саф күңелдән әйтелгән киңәше белән кай вакытларда ата-ананңы да алыштыра алучы якын дустың гына, тигез булып, матур булып, сине тын утырырга мәҗбүр итеп, һәр сүзне күңелдә калдырырлык итеп әйткән ачык, көмеш кебек чыңлап чыккан тавышы яңгырый.

Ул мине дә тәрбияләде. Авыр минутларда күңлемне төшермәскә, җиңеп чыгарга өйрәтте. Минем өемә килде, ата-аналарым белән сөйләште. Әгәр нәрсәм дә булса җитешми икән, аны алырга акчам булмый икән, ул ничек итсә итте—мин, бу зур дустымның кайгыртуы аркасында, кирәк әйберле булдым. Киңәшкә дип мин генә түгел, минем әти-әниләрем дә аның янына килә иде. Ә ул алар белән чын күңелдән сөйләште, аларның сүзләрен үзендә саклады.

Бу карт укытучының исмен җылы итеп, бик якын итеп һәм шатлыклы елмаеп әйтәсең...

Мин быел гына X нчы классны тәмамладым. Ләкин хәзер кайда гына укысам да бу якын дустымны онытмам! Минем чәчемә дә чал керер, минем маңгаем да җыерчыкланыр, әммә аның исме күңлемдә элеккечә җылы булып сакланыр. Шул бит миңа язарыма каләм бирде. Һәр яңа хикәя, һәр яңа повестым белән мин аңа бурычлы. Минем ул хезмәтләрем үземә түгел, ә аңа--минем укытучыма—Семен Ионовичка дан китерсен, ул укыта торган мәктәпкә дан китерсен. Аның дәресендә, ул сөйләгән сүзләр тәэсирендә кулыма каләм алдым мин. Әгәр ул үзе рөхсәт итсә, үземә бай тәҗрибә җинагач, һич шиксез, мин аның турында зур һәм бик матур әсәр язар идем.

Кайчакларда син күңелсезләнәсең. Семен Ионович синең яныңа килә:

— Син нәрсә борныңны салындырдың әле?—ди ул. Шат бул! Әйдә, булмаса, синең белән әнә теге бүлмәгә керик, я йөреп килик.

Син йөреп киләсең. Инде синең борның салынмаган, синең күзләрең шаян ялтырыйлар.

Ниндидер малай сарай артына бара. Сарай артыннан төтен күтәрелә башлый. Ә бераздан туктый. Йөткеренә-йөткеренә, малай сарай артыннан чыга, мәктәпкә керә.

Семен Ионович, шаян елмаеп, аның каршысына килә:

— Сарай киптерденме әллә?—ди малайга, исме белән дәшеп. — Сараең кипкән булгач, синең кәеф шәптер инде. Кәеф шәп булгач, минем белән, менә биредә генә, сөйләшеп алудан да баш тартмыйсыңдыр. Семен Ионович малайны оялдыра. Тәмәкенең бик зарарлы булуы турында сөйли. Малайны ышандыра.

Берәр бала дәрестән артта кала башлый икән, ул моңа да кирәкле юл таба. Малайның өенә бара, аның өчен консультацияләр оештыра, яхшырак укучыны аңа беркетә.

Аның классындагы балалар материалны яхшы үзләштерәләр. Семен Ионовичның атаклы сүзе бар: тәртип юкта—эш тә юк!—ди ул. Бу сүзне һәр укучы хәтерли, үз-үзенә, иптәшенә контроль ясап тора.

Балаларга якын килә, һәр нәрсәне үз вактында күрә белүе аркасында кучмә эмблема һәр вакыт аның классында булды, класста утырып калучылар юк. Иң күп отличниклар саны алар классында.

Кадерле Семен Ионович!

Синең утыз биш еллык хезмәт юбилеендә, синең хәзерге укучыларың гына түгел, кайчандыр синдә укыган, хәзер инженер, врач, язучы-шагыйрь, укытучы булып әверелгән һәм әле ВУЗда укый торган студентлар, синең исмеңне үз итеп, якын итеп, бик яратып искә алалар.

— Озак яшә балалар рухының инженеры!—диләр алар.—Син данлыклы эш алып барасың—коммунизм җәмгыятен төзүчеләрне тәрбиялисең.

Гарәфи Хәсәнов.

ПЕДАГОГИЯ ЭШЕНДӘ 35 ЕЛ

Семен Ионович Ионинның педагогия өлкәсендәге хезмәтенә быел 35 ел тулды. Бу чор эчендә иптәш Ионин бик күп балаларга, бик күп яшь үсмерләргә тәрбия бирде. Алар инде хәзер инженерлар, техниклар, врачлар һәм башкалар булып җитештеләр. Безнең социалистик төзелешнең активлары булып әверелделәр.

Семен Ионовичтан тәрбия алган һәрбер бала, һәрбер яшь үсмер бу ягымлы, эшлекле, йомшак күңелле укытучыны һич кайчан да онытмый. Һәр вакыт мактап искә ала.

Семен Ионович безнең урта мәктәптә 1934 нче елдан бирле эшли. Ул биредә дә үзен иң яхшы, алдынгы, үз эшенә бирелгән булуы белән танытты. Ул балаларны чын күңелдән ярата. Һәр вакыт балалар арасында булырга тырыша. Укучыларының көндәлек хәлләре белән, семья тормышлары белән якыннан кызыксына. Үзенең туганнарча киңәшләре белән балаларга да, ата-аналарга да якын килә белә.

Бик күп ата-аналар балаларын тәрбияләү турында иптәш Ионинннан күп файдалы киңәшләр алалар.

Иптәш Ионин рус теле укытучысы. Ул үз фәнен бик яхшы белә. Шулай ук укучыларның да бу фәнне тирәнтен үзләштерүләрен тәэмин итә ала. Ул үз фәне буенча көчле укытучылардан санала. Аның эш методлары күпләргә үрнәк.

Семен Ионович үз эшен, балаларны һәм туган ватанны нык яратуы, эшенең һәрбер тармагына намус белән каравы нәтиҗәсендә һәр вакыт уңышларга ирешеп тора.

Ул җитәкчелек итә торган VII нче класс быел мәктәп күләмендә беренчелекне алды. Социалистик ярышның уңышлы куелуы нәтиҗәсендә бу класста дисциплина да, өлгереш тә яхшы булды. VII нче класс укучылары сынаулар вактында да сынатмадылар. Класстан 100 процент күчүгә ирештеләр.

Менә шушы хезмәтләре өчен дә Семен Ионовичны мәктәптәге барлык укытучылар, барлык балалар хөрмәтлиләр һәм зурлыйлар.

Шуның өчен дә аның мактаулы хезмәтенең 35 еллыгын без бергәләп бәйрәм итәбез.

Без Семен Ионовичның озак яшәвен, педагогия эшендә тагын да мактауларга ирешүен телибез.

Хисам Садыйков.

Мәктәп директоры.

Якын дус

Минем Семен Ионовичта алган белемем нык нигезле булып чыкты. Ул миңа үсәргә һәм бөек рус халкы телен тагы да кызыксынып өйрәнергә юл ачты.

Мин Семен Ионовичны укытучым итеп кенә түгел, якын дустым һәм туганым кебек итеп искә алам.

Ул әле дә очрашкан вакытта бик якын һәм ягымлы итеп сөйләшә. Ул барысы белән дә кызыксына. Укуларның барышы, тормыш хәлләре, җәйге ялны уздыру турындагы перспективаларны һәм башкаларны сорый. Сөйләп бетергәнне аталарча тыңлап тора да бик матур киңәшләр бирә.

Кай вакыт мәктәп елларындагы шаянлыкларны искә төшереп көлдереп тә ала.

Семен Ионович кешенең йөрәгенә керә белә. Шуның өчен дә ул үзенә мәхәббәт тудыра һәм яраттыра. Аның белән булган очрашу укуга һәм яшәүгә дәрт арттыра. Күңелне күтәрә.

Мин бу кадерле укытучымның тагын да озак яшәвен, коммунизм җәмгыятен төзү өчен үзе кебек намуслы, акыллы, зирәк һәм көчле кешеләр тәрбияләп үстерүен телим.

Р. Вәлиев.

Казан, Коммуналь төзелеш инженерлары институты студенты.

СЕМЕН ИОНОВИЧКА

(Юбилей уңае белән)

Инде күптән ярты төн авышкан,
Стаканда чәең суынган.
Тәрәзәдән кергән бер тавыш та
Бүлә алмый татлы уеңнан.
Бөтен шәһәр йоклый инде тынып,
Ә син ялгыз өстәл читендә
Утырасың эшкә, уйга чумып,
Нурлар уйнап синең битеңдә
Яктырталар тормыш эзләрен,
Я моңаеп, я елмаеп куя
Шәфкатле һәм шаян күзләрең.
Укучының нәни кайгысын да,
Шатлыгын да бергә бүләсең.
Син җылытып кояш яктысыдай,
Сабый йөрәгенә керәсең.

Күңлең булмый җиңү эзләренә
Сабыйларны юллап кертмәсәң,
Йокы керми синең күзләреңә
Диктантларны карап үтмәсәң.
Көмешләнгән чәчең артка тарап,
Бер минутка уйга каласың.
Зәңгәр күктә йөзгән айга карап,
Гомерең юлын искә аламсың?
Хәтерлимсең үскәч канатланып
Сабыйларның очып китүен,
Очраганда инде бик шатланып
Кулларыңны кысып үтүен?

М. Әхмәтгалиев.

Семен Ионичның элекке укучысы, хәзер Педагогия Институты студенты.

Семен Ионович балаларның иң яхшы дусты. Ул алар белән туганнарча җылы һәм ягымлы итеп сөйләшә. Аларга матур-матур киңәшләр бирә. Рәсемдә: С. И. Ионин балалар белән.

ТИМЕРЧЕ ЙОСЫФ

КАВИ НӘҖМИ

Худ. Г. Арсланов рәсемнәре

(Дәвамы. Башы 44, 45 нче номерларда)

Кем икән бу?—дип әйләнеп карауга, чым кара чәчле, карлыган төсле матур күзле ят бер кызның кул изәвен күрде.

— Кем син?—диде Йосыф аңар.

— Анда синең эшең булмасын!—диде кыз. Бу өрәңге минеке. Бу урман минеке. Бабайдан мирас булып калган байлыклар алар.

— Әһә!—диде Йосыф. —Алпавыт кызы икәнсең. Алай булгач бу өрәңгене син кистерденмени?

Кыз тагын да якынрак килеп, күкрәген киереп әйттте:

— Бу җир минеке!... Кем рөхсәте белән син монда агач утырттың? Кем соң син?

Йосыф аңар ярсулы тавыш белән җавап кайтарды:

— Кыздыручы, бөгүче, кызу чакта сугучы Йосыф булырмын мин. Эшләмәгән кешегә җир дә, урман да булырга тиеш түгел. Мин эшлим. Шулай булгач минем агач утыртырга да, чәчәк үстерергә дә һәм алардан файдаланырга да хакым бар. Берсен кискәннәр икән, икенчесен утыртырмын. Ансын киссәләр, яңасы үсәр.

—Үстереп кенә кара!—диде кыз һәм ул бу сүзне ачулы тавыш белән әйтте.

— Үстерербез!—диде Йосыф аны үчекләп.—Синнән сорап тормабыз.

— Хәзер үк калдырып кит!—диде кыз һәм ике куллап агачка ябышты. Йосыф өрәңгене бер селтәнү белән аның кулыннан тартып алды да, балтасын билбауга кыстырып, авылга юнәлде. Биш-ун адым китәргә өлгермәде, каршыга килеп баскан коточкыч зур бүрене күреп, аптырап калды. Уңга борылмакчы иде, икенче бүрегә очрады. Сулга караса, анда да бүре... Ничек котылу турында уйлап артка әйләнгән иде, кара чәчле кыз кулларын чәбәкләп, шаркылдап көлеп җибәрде:

— Әйттем бит мин сиңа, калдыр дип!

— Калдырмыйм!—диде Йосыф һәм бөтен яклап әйләндереп килүче бүреләрне балта белән каршы алырга хәзерләнеп, урман яңгыратып кычкырды:

— Бирмим мин сезгә өрәңгене!

Бәлки ул сугышкан да булыр иде, каршыга урман кызы чыгып, баягыдан йомшак тавыш белән эндәште:

— Әйт, зинһар, нәрсәгә кирәк булды сиңа ул агач? Син бит тимерче.

— Көянтә эшлим!...—диде Йосыф.

Кыз бик гаҗәпсенгән тавыш белән сорады:

— Көянтә? Кемгә ул көянтә?

— Ансы сер!—диде Йосыф.

— Серең кирәк түгел миңа. Әйтә торган сүзем шул гына: авылга исән-сау кайтасың килсә, миңа да бер көянтә эшләп кит! Өрәңгесен үзем бирәм. Бусы синдә калсын. Ризамы шуңар?

— Риза!—диде Йосыф.

Шулай әйтүгә кыз иң зур бүрене бармак белән генә ымлап чакырды да, Йосыфка шул бүре өстенә атланырга кушты.

Әле генә куркыныч кыяфәттә тешләрен ыржайтып торган зур гәүдәле бүре кинәт юашланды, өйрәтелгән тай төсле тын гына атлал килеп, Йосыф янына туктады. Кыз үзе дә шул ук бүрегә Йосыф белән янәшә утырды.

— Киттек, әйдә!

Калган бүреләр, бер-бер артлы тезелгән килеш, аларны озатып бардылар.

Кызык юл булып чыкты бу. Каршыга очраучы төлкеләр, ботакларда тирбәнүче тиеннәр йонлач коерыкларын болгап сәлам бирәләр. Карт агачларның черек куышларында утырган мәче башлы ябалаклар, төмтүгәрәк күзләрен фонарь төсле яктыртып, аларга юл күрсәтәләр. Озын колаклы соры куяннар „Менә моннан турырак!“ дигәнсыман, аларның алдына ук төшеп йөгерәләр.

Шуларны күзәтеп бара торгач, кич җиткәне сизелми дә калды. Әллә ни арада гына кояш батып, ай калыкты. Кеше аягы тимәгән кыргый урыннардан борылып-сырылып баручы аю сукмагына куе караңгылык төште.

IV.

Бүрегә атланып бару күпме генә кызык тоелса да, юлның озынлыгы, вакытның соңлыгы Йосыфның эчен пошырып, йөрәген борчый башлады. Тагын бераз баргач ул:

— Еракмы әле? — дип сорады.

Кыз бик сәер генә елмаеп әйтте:

— Каенлыктан үткәнче, өрәңгегә җиткәнче!

Бу сүзләр Йосыфка тагын да шомлырак тоелдылар һәм ул ничек кенә итеп булса да кайтырга ашыгып, кызга эндәште:

— Бик соң инде хәзер. Минем бит эштән генә килеш... Арганмын да, сусаганмын да...

— Шәйлисеңме утны?—диде кыз,—шунда җиткәч туктарга да мөмкин.

Яфраклар арасыннан челтәрләнеп сары яктылык сузылды. Озакламыйча алар капка төбендәге баганага, чылбырлап аю бәйләнгән өр яңа йорт каршына килеп чыктылар. Бүреләр шунда ук агач араларына таралып, күздән югалдылар.

— Бу минем өй!—диде кыз.—Һәр елны мин, агачлар бөреләнә башлагач та, бирегә киләм. Яфраклар саргаеп коелганчы әти белән бергәләп шушында яшим.

Йосыф ачык тәрәзә турысына утырган аеры сакаллы картны күрде. Аның кулында ниндидер бер мылтык бар. Тора торгач ул шуны өстәлдәге шәм яктысына тотып, көпшәсе аркылы утка карый. Ишекне ачып керү белән кыз аңар:

— Менә сиңа тимерче Йосыф!—диде.

— Ишеткәнем бар,—диде карт.—Әгәр дә син чыннан да тимерче булсаң, менә бу мылтыкны тикшереп кара әле!

Йосыф мылтыкны кулга алу белән үк чакмасындагы тоткарлыкның сәбәбен тапты һәм шунда ук төзәтеп тә бирде. Карт аның осталыгына кәефләнеп:

— Болай булгач мин сиңа бер төлке атып кертим. Бүрек эшләтеп киярсең һәм киләчәктә дә мин кушкан йомышларны шулай эшләп йөрерсең!—диде һәм мылтыкны күтәреп чыгып та китте.

(Дәвамы бар).

Казандагы 1 нче номерлы урта мәктәпнең яш натуралистлары биология кабинетында. Уртада биология укытучысы иптәш И. Ф. Разумовская. Сәйфеттинов фотосы.

БАЛА ШАТЛЫГЫ

Сөенә ул бүген, сикергәли,
Күкрәгенә сыймый шатлыгы,
Киң урамнар буйлап безнең Гали,
Җырлый-җырлый үтә атлыгып.

Күн портфелен кыскан күкрәгенә,
Йөзләренә алсу нур кунган.
Көлә аның матур күзләре дә,
Нигә шатлана ул, ни булган?

Кайтып керде дә ул өйләренә,
Тиз-тиз генә өстен чишенде.
Күмелеп ул шатлык хисләренә
Ана кочагына сикерде.

Чын күңеленнән сөйде, кочаклады,
Кат-кат үпте сөйгән анасын.
Бу күренешкә ана аптырады
Озак карап торды баласын.

Ялкынланып бала сүз башлады
Аның сүзе сүзгә бәйләнгән.
— Әни, бүген минем шатлыгым зур,
Отлично алдым барлык фәннәрдән.

Алган йөкләмәмне үтәдем мин,
Тормышка ашты минем теләгем.
Отличного гына укуларым
Сөекле әнкәм, сиңа бүләгем.

Нәкыйп Дәүләтшин.

Үзең ясарга өйрән

„ЖИЛ ТЕГЕРМӘНЕ“



Киң генә бөке алып, шуның уртасына тишек тишегез һәм кисеп каз каурые куегыз. Бу сап бөке өстеннән ике якка да (аскы һәм өске якларга) чыгып калырга тиеш.

Бөкенең янына тигез аралар калдырып, тигез зурлыктагы каурыйлар кадап чыгарга кирәк.

Барлык каурыйлар да бер якка таба авышрак куелалар.

Шуннан соң инде уртага куелган каурый сабының уртасыннан кадак уздырыла. Ул кадакка агач беркетелә.

Тегермән кадакта җиңел әйләнер.

Әгәр тегермән ясый башлаганчы каурыйларны буясаң тегермән бигрәк тә матур була.

ТАБЫШМАКЛЫ УЕН

ИКЕНЧЕ СЕРИЯ—„Б“ ХӘРФЕНӘ

1. Химик элемент.
2. Гади күз белән караганда күреп булмый торган организмнар.
3. СССР дагы күл.
4. Европадагы диңгез.
5. СССР дагы Союзный республика.
6. СССР дагы шәһәр.
7. Германиянең баш шәһәре.

Хәммәт Әхмәтҗанов.

Кама Тамагы районы, Олы Карамалы урта мәктәбе.

Җаваплы редактор Г. ХӘБИБУЛЛИН.
Ответственный редактор Г. ХАБИБУЛЛИН.

Редакция адресы: Казань, ул. Баумана, Дом Печати, 2-й этаж, ком. № 5, 6, 7. Хатлар җибәрү өчен адрес: Казань, 10, Абонементный ящик № 87. Редакциянең телефоны № 18—78.

Аерым саны 5 тиен, 3 айга 1 сум 20 тиен, 6 айга 2 сум 40 тиен, бер елга 4 сум 80 тиен.

Тип. им. Н. Александрова г. Казань, 1940 г. Упол. Главлита ТАССР № А—1868. Заказ № 2272.